**ГЛАВА БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 ноябрь, 2021 ел Олы Подберезье авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Плетени торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Плетени торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Плетени авылы, Ленин ур. 55 йорт адресы буенча урнашкан Плетени авыл клубы бинасында 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Олы Подберезье авыл җирлеге Плетени торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

б) Халыкны су белән тәэмин итүне җирлек чикләрендә оештыру:

- су җыю скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә Олы Подберезье авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) очракларын кисәтү һәм таратмау өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы О.М. Емельянова